ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза,
422586

Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагуҗа авылы,
422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

03.12.2025　　　　с. Коргуза　　　　03

Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең
Карагуҗа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

“Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 16 декабрендә 10 сәг. 00 мин.ка Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авылы җирлеге гражданнары җыелышының беренче этабы дип билгеләргә.
2. 2025 елның 16 декабрендә 13 сәг. 00 мин.ка Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авылы җирлеге гражданнары җыелышының икенче этабы дип билгеләргә.
3. 2025 елның 16 декабрендә 14 сәг. 00 мин.ка Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авылы җирлеге гражданнары җыелышының өченче этабы дип билгеләргә.

4. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.

1 этап: Үзәк, Пролетарская, Боевая, Яшьләр урамында яшәүчеләр.

2 этап: Беренче Май, Садовая, Октябрь урамында яшәүчеләр.

3 этап: Заречная, Яр буе урамында яшәүчеләр.

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Карагуҗа торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

(Карагуҗа авылында юлларны ремонтлау өчен асфальт гранулят һәм вак таш сатып алу, товарны билгеләнгән пунктка илтеп җиткерү белән тәэмин итүче исәбеннән).

«ӘЙЕ» «ЮК»

6. Халык җыеннарын үткәрергә:

1 этап: Карагуҗа авылы,Үзәк урамы буенча урнашкан кибет яны чатында;

2 нче этап: Карагуҗа авылы, Үзәк мәйдан урамы буенча мәктәп гаражы янында;

3 этап: Карагуҗа авылы, Набережная урамындагы 15 нче йорт янында;

7. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д.В.Плохов